**Кукмара муниципаль районы**
**Починок-Кучук авыл башкарма комитеты**

# КАРАР

**«30» гыйнвар, 2020 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары, «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлегендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл башкарма комитетында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 31 июлендәге 18 номерлы карарын 2020 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче: Ф.А. Гайнутдинов

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Починок-Кучук
авыл җирлеге башкарма комитетының
2020 елның 30 гыйнвары
1 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2020 елның 1 февраленнән**
**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлектәге хезмәтләрнең**
**бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2615,56 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетне) зиратка илтү | 841,72 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2667,58 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Починок-Кучук
авыл җирлеге башкарма комитетының
2020 елның 30 гыйнвары
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

**2020 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук
авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлектәге
хезмәтләрнең
бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү (киендерү) | 110,12 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2505,44 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 841,72 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2667,58 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |